ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

03 июль 2026 ел

№ 6654

Башкарма комитетның «Даими муниципаль маршрутлар буенча шәһәр җир өсте электр һәм автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны (чыгымнар өлешен) кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында» 2026 елның 13 мартындагы 2371 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Даими муниципаль маршрутлар буенча шәһәр җир өсте электр һәм автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны (чыгымнар өлешен) кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында» 2026 елның 13 мартындагы 2371 номерлы Карарының 2 пунктына, «12 000 000,0» цифрларын «165 000 000,0» цифрларына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов